Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ МАЙ • 2022 • КАЗАН

5



Александр АЛЁШИН

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ

КИТМИБЕЗ

Олы буын бакыйлыкка күчә –
Сафлар сирәгәя, кимибез,
Саегабыз, аркадашлар китә,
Ярлылана милли телебез.
Яңа буын – сәер буын килә!
Милләтең ни аңа, телең ни...
Милләтеңне кимсенүдән йолыр
Яшәү уты ике бирелми.
Милләтеңне үзең зурламасаң,
Зурлыгыңны белмәс бирәү дә.
Милли горурлыгың нигә зәгыйфь?
Ник эленеп тора тирәүдә?
И, милләттәш! Бабаңнарың рухын
Сансызлыгың белән рәнҗетмә!
Татарлык ул: "Помолитесь!" – диеп,
Хәер сону түгел мәчеткә.

ЭЛЕК һӘМ ХӘЗЕР

Кыңгыраулы тальян гармун тартып,
Кызлар күзләгәннәр бабайлар.
...Сыра йотып, сигаретлар тартып
Урам уза буйдак малайлар.
Чигү чигеп, бирнә ясаганнар
Кыз чагында безнең әбиләр.
...Гуләйт итеп, йөккә узалар да,
Җәфа чигә үсмер әниләр.

ШИГЫРЬ АТЫ

Шигърияттә ат уйнаткан агайлар кимеп бара,
Ат уйнатыр яшь-җилкенчәк мәйданнан китеп бара.
Юртакларын бастыралар сукага – җир сөрергә.
Чиләнә шулай шигъри ат, кала сөяк-сеңергә.
Йөк тартырга җигелгәч бер тулпар өзлегә, янып.
Юртакларын камчылаучы илгә булмый таянып.
Җигәләр илһам пегасын әҗерсез кара эшкә.
Шигырь мәйданы тарая, азына кара көчләр.
Телгә кизәнүче күсәк төшә шигърь сыртына.
Меңьяшәр әдәбиятның күңел күзе кысыла.
Кеше кадере беткәндә кайдан килсен сүзгә сан,
Цензурасыз сүз иреге, бәйсез милли хөр үзаң?
Сүзгә кадер була диме, булмаганны кешегә?
Юаш әдәби алаша төс безнең көнлекчегә.
Меңьяшәр шигырь атының
какшап төшкән тешләре.
Моңсу күзләренә бактым,
җаным әллә нишләде.



Ринат АБЗАЛОВ



ШОМБАЙ *болай диде...*

Хөрмәтле Чаян! Күптән түгел куркып чит илгә «тайган» шоу-бизнес әһелләренең Россиядәге эшчәнлекләрен туктатырга җыенмаулары турында белдем. Галкин, мәсәлән, сентябрьдә Казан «Пирамида»сында концерт бирергә җыена, ә Меладзе безне ноябрьдә бәхетле итмәкче икән...

Л. ТӨХФӘТУЛЛИН

КАЗАН

– Бу һич тә гаҗәп түгел, – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач. **– Бу «йолдызлар» күптән инде бер кагыйдә буенча яши: безнекеләргә дә, сезнекеләргә дә җырлап-биергә әзер! Түләсеннәр генә...**

Александр БРЮХАНОВ

ИНТЕЛЛИГЕНТЛАР ҮРЧЕТҮ

Калмады бездә чын интеллигенция. Каядыр инде, юкка чыкты. Бу мәсьәләне берәр ничек хәл итәргә кирәк бит...

Башта фәнни шәһәрчекләрдә һәм институтларда аның сакланган калдыкларын җыеп, шигырьләр һәм гитаралы җырлар концерты белән кызыктырып бер урында җыярга...

Барысын да язып алырга, чәйле өстәл янында тарихларын тыңларга... Балалары, оныкларының кайда икәнен белергә...

Әбер төнне көтмәгәндә яшьрәкләрен эләктереп алырга да, "Интеллигент" дип аталган махсус лагерьда җыярга. Яннарына телевидениедә төрле интеллектуаль уеннарда катнашкан яшь ирләрне һәм консерватория тирәсендә яшәүче хатыннарны җибәрергә...

Яхшылап киендереп, "Тарихта интеллигенциянең роле" темасына конференция уткәрергә, бер-берсе белән якыннан танышсыннар.

Аннан соң "Әхәзер нишләргә?" дигән диспут оештырырга...

Әахырда җирле диджейлар эшкәртүендәге классик концерт бирергә, беткәч танцы ясарга...

Төнлә "Көтелмәгән якынлык" фильмы күрсәтү...

Һәм бик тиз алар үзләрен интеллигент дип санаган кешеләр әйтергә дә кыймый торган нәрсәләр эшли башлаячаклар. Шулай итеп мәсьәлә җиңел генә хәл ителәчәк.

Вячеслав ШИЛОВ





Игорь КИЙКО



Курку белмәс браконьерлар

Борын-борыннан ауга йөрү кешенең төп эше һәм азык чыганагы булган: әгәр даими рәвештә яшәгән куышлыгың каршына мамонт сөйрәп кайтмасаң,үзеңнең һәм гаиләңнең ачлыктан тәпи сузуыңны көт. Ул вакытлардан йөзләгән гасырлар узды, һәм бу хәвефле шөгыльне янәшәдәге супермаркетка "сәяхәт" алыштырды. Әмма борынгы ата-бабалардан канга сеңеп калган гадәт беркая да китмәде, бары тик ул чактагы сөнге һәм ук-җәяләрдән күпкә җитдирәк ау чаралары барлыкка килде. Хәзерге лазер мылтыклары, җәнлекләрне чакыра торган электрон җайланмалар һәм тепловизорлар очраган кыргый тугандашларыбызга качып котылырга мөмкинлек калдырмый. Ә инде бу эшкә бернинди ерткычлардан да, сакчылар һәм законнардан да курыкмый торган браконьерлар тотынса...

Ике ел чамасы элек Татарстанның икътисадый җинаятьләр белән көрәш Идарәсе хезмәткәрләре Тәтеш районында кабаннарны атып йөрүче аучылар төркеменә тап булганнар. Алар ауны шулкадәр ачык алып барганнар ки, кайберәүләр аларның олы яклаучылары бардыр, дип сөйләгәннәр. Ләкин аңа карамастан, барыбер законсыз сунарчыларга карата җинаять эше кузгатып, "хезмәт коралларын" – куәтле машина, затлы мылтыкларын, патроннарын, ау этләрен конфискацияләгәннәр.

Югары Ослан районында машинада ике атылган кабан алып кайтып барган ике браконьерны тоткарлаганнар. Алар кыргый дуңгыз итеннән авыз итәргә өлгермәгәннәр: табышны алганнар, ә үзләрен штрафка тартканнар. Кабаннар хәзер арзан түгел – законсыз ау өчен 180 мең сум түләргә һәм моңа кадәр тапсыз булган абруйларын югалтырга туры килгән.


Самарадан килгән ике дус Лаеш районындагы аудан соң иптәшләре алдында үтә бай табыш белән мактана алган булырлар иде: аларга ике пошине, өч кыр кәҗәсе һәм кабан тәтегән. Тик мактанырга өлгерми калганнар. Рөхсәтсез сунар өчен аларга 1,3 миллион сумнан колак кагу өстенә, суд эскәмиясенә дә утырырга туры килмәгәе. Ә Кызыл Октябрь аучылык хуҗалыгында исә тагын бер бәндәне урманчы поши тиресе тунаганда эләктергән...

Ауның балык тотудан кабымлык төре белән генә аерылганын моның белән шөгыльләнүчеләр яхшы белә. Шуңа күрә балыкчылар аучы туганнарыннан артта калмыйлар. "Свияжский" тыюлыгында өч ел чамасы рәсми рөхсәтсез балык тотканнар. Шунысы кызык, иң балыклы урыннарны тыюлыкның башлыгы үзе күрсәткән. Ул браконьерларга җаваплылыктан китәргә дә ярдәм иткән. Тикшерүчеләр хәтта ришвәт бирү очрагы да тапканнар – закон бозучыларны үз канаты астына алган өчен ул бүләк алган: аракы, шоколад һәм бер шешә газлы су.

Якынча шул ук вакытта Актанышта хокук сакчылары җәтмәсенә чын мәгънәсендә артель оештырган кысла тотучы эләккән. Затлы табигать бүләкләре хәтта Мәскәү өстәлләренә дә барып җиткән, һәм бу бизнестан алган табыш 20 миллион сумга җиткән. Тагын бер төркем кысла тотучылар Болгарда капкан. Боларының эшчәнлеге тыйнаграк булган: алар чал Идел суларыннан "бары тик" 2,6 миллион сумлык 20 мең кысла чыгарганнар.

Табигать ресурсларын саклау эше ел буе, төрле юнәлешләрдә бара. Белгечләр исәпләвенчә, узган ел эчендә генә браконьерлардан 140 мең тонна балык коткарып калынган. Законсыз сунарчыларның "тырышуына" карамастан, кыргый җәнлекләрнең саны арта бара, ә бу, үз чиратында, намуслы аучыларны лицензияләр белән тәэмин итү мөмкинлеген киңәйтә. Ә эшләр болай барса, киң таралган "Хайваннарның иң куркынычы – кеше" дигән әйтемнең кулланудан чыгуы да мөмкин.

Людмила САФИУЛЛИНА



Валерий ТАРАСЕНКО

Борис ДЁМИН



Вячеслав ШИЛОВ



Илдар НӘФИЕВ





• • •

Доллар күтәрелде – бәя үсте, доллар төште – бер генә хәшәрәт тә бәяне төшерми. Димәк, эш долларда түгел, ә хәшәрәтләрдә.

• • •

– Мин барлык хатын-кызларны әкият сөйләп яулап алдым...

– Ә мине әкият белән алдый алмассың!

– Алмыйммы! Чөнки син башкалар кебек түгел! Син искиткеч гүзәл, мин синең кебекләрне моңарчы күргәнем дә булмады!

• • •

28 ел буена беренче мәртәбә депутатларга һәм түрәләргә менә шушы елларда үзләре барлыкка китергән шартларда балаларын укытырга, дәваларга, яшәргә өйрәтергә туры киләчәк.

• • •

Бер әби тайгак урыннан әйләнеп үтүне кирәк таба, кызганыч, ачык люкка егылып төшә. Ярый әле анда люк тулы әбиләр җыелган икән, ул аягын гына сындырган.

• • •

– Бүген температура ничек?

– Күләгәдә алты градус.

– Ә кояшта?

– Алты миллион...

• • •

– Үскәч синең кем буласың килә?

– Космонавт.

– Космонавт булыр өчен озак итеп, яхшы укырга кирәк.

– Юк, мәҗбүри түгел. Белка белән Стрелка укыганнар дип беләсеңме?

• • •

– Ник елыйсың?

– Әле генә черкине үтердем.

– Шуннан нәрсә?

– Бәлки кенәз Гвидон булгандыр ул?

• • •

Ире төнгә балык тотарга җыенганда хатыны моңа:

– Дусларыңның кайсысы белән барасың соң? – ди.

Ире:

– Үзем генә барып тотасым килә әле, – дип җавап кайтара.

Абау!

КЫЙММӘТЛЕ УЕННАР

Казанда Самарадан һәм Ульяновск өлкәсеннән килгән дүрт бәндә финанс эшләре алып барырга һәм криптобиржада уйнарга теләүчеләрне өйрәтергә булганнар. Эшләр шулкадәр шәп киткән ки, республика башкаласында фирманың өч филиалы ачылган. Замана белеме таратучылар башлаучы уенчылардан фонд базарында акча эшләү өчен бишәр мең доллар җыйганнар. Кесәләре юкарак булганнарга кредит белән ярдәм иткәннәр. Ләкин җыелган акчалар биржага барып җитмәгән, финансчы мөгаллимнәрнең кесәсендә утырып калган. Финанс эшенең нечкәлекләренә 80 казанлы төшенергә өлгергән. Мошенниклар исә аларны барлыгы 53 миллион сумга өткәннәр.

ОЛЫ ҖАНЛЫ ПРИСТАВ

Татарстанда сирәк күренешкә тап булганнар – ул да булса кеше сөючән пристав. Татарстан суд приставлары идарәсенең Алабуга район бүлегендә хезмәт куючы ханым клиентларының бурычларын "гафу итеп" барган. Документларда бурычы булганнар белән барысы да тәртиптә, дип күрсәтеп, ул башкару эшләрен туктаткан. Әмма төпле тикшерүдән соң эшнең ханымның олы җанлылыгында түгел, ә шәхси кызыксынуында булганлыгы ачыкланган. Шулай итеп, пристав үзенең эш күләмен киметеп, волокита өчен начальниклардан шелтә алудан сакланган.

ПОЧТА БӘЛАСЕ

Яшел Үзән районының Бело-Безводное, Раифа һәм Садовый бистәләрендә яшәүчеләргә, пенсия йә ЖКХ квитанциясе алу өчен шәһәргә йөрергә туры килә. Якындагы почта бүлеге ябылган, ә почтальон эштән киткән. Кайчагында килгән кәгазьләрне шундагы кибетләрдәге тартмаларга салалар, ләкин алар аннан еш кына югалалар. Хакимият, "бу безнең эш түгел", дип, мәсьәләне хәл итүдән баш тарта, ә шәһәр почтасында үзләренә почтальон эзләргә тәкъдим итәләр. Тик менә тиеннәр өчен авыр букча асып йөрергә теләүчеләр нишләптер юк.

СӘЛӘТЛЕ ШӘКЕРТЛӘР

Актанышта барыбызга да билгеле булган Чичиковның эшен дәвам итүчеләрне тапканнар. Мондагы технология техникумы фиктив рәвештә 44 студент кабул иткән. Документлар буенча "үле җаннар" 2014 елдан 2019 елга кадәр технология нечкәлекләрен өйрәнгәннәр. Алар шәп укыганнар, хәтта диплом эшләре дә яклаганнар. Бу хәйлә укыту программалары өчен субсидияләр алу, кабул итү планын үтәү һәм коллективка премияләр бирү өчен корылган булган.





Нәни елмаюлар

АКЫЛЛЫ КЕШЕ

– Усман әфәнде – бик акыллы кеше. Аның бөтен нәрсәгә үз фикере бар.

– Шулайдыр, чөнки ул акылын һәм фикерләрен әрәм-шәрәм итеп йөрми, эчендә саклый. Шуңа күрә аның акыллы булуы гаҗәп түгел.

САРЫК БИТ УЛ

Берзаман автохуҗалык шоферлары тартырга утырганнар һәм юл кагыйдаләрен бозу турында гәп сатарга керешкәннәр. Араларында иң өлкәне булган Исмәгыйль болай дигән:

– Менә мин утыз ел машина йөртәм, бер тавык та таптатканым юк.

Икенче шофер, Салих, сорап куйган:

– Ә узган ел бәрдергән сарыкны оныттыңмыни?

– Һи, ул сарык бит, тавык түгел, – дип җавап биргән Исмәгыйль.

МАКТАНЧЫК АУЧЫ

Кайчандыр төлке аткан аучы мактана икән:

– Аның койрыгы гына өч метр бар иде!

Аның ялганлаганын белгән күршесе үзе дә борчак сибә башлаган:

– Улымның туена биш сарык китте!

Аучы җавап бирә:

– Нәрсә инде юкны сөйлисең? Бераз кимет инде.

– Син дә кимет, – дигән күршесе.

– Койрык ике метр чамасы булгандыр...

– Мин дә киметәм. Өч сарык.

– Тагын кимет, – дигән аучы.

– Син дә...

– Барыбер бер метр бар иде.

– Ә мин бер генә сарык суйган идем, – дигән күршесе.

ҮЗЕМ ӨЧЕН

Хуҗа көтеп алынган кунакны җибәрергә теләми икән.

– Елына бер киләсең, шунда да китәргә ашыгасың. Тагын бер өч көн тор инде, безнең өчен шатлык булыр.


Кунак тагын бер атна торган. Хуҗа әйтә икән:

– Синең белән күңелле дә бит, ләкин миңа урманга утынга барырга кирәк...

Кунак югалып калмаган:

– Бер атна хуҗаны шатландырып тордым, хәзер бераз үзем өчен шатланып яшим инде.


Александр ЛЕВИТИН


Василий АЛЕКСАНДРОВ



ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ

Вячеслав ШИЛОВ



Алмаз ХӘМЗИН

ЧИР

Авырмаган кеше юктыр
Бу хәзерге заманда...
Заманы да чирле аның,
Әллә нинди – зар-моңда...

Элек бар иде халыкта
Барлыгы дүрт чир-сырхау:
Баш кизүе, эч кизүе,
Теш сызлау да һәм аксау.

Яу чаптылар безгә күпләр,
Гарипләндек, үлделәр...
Чирләп түгел, кан коюдан...
Батырларны күмделәр...

Санга сукмый авырулыгын
Тыл эшләде көне-төн.
Әби-бабай, хатын-кызлар,
Бала-чага җиңү көтте
Өзеп соңгы телемен.

Тынмый әле һаман яулар,
Чыга төрле афәтләр.
Пандемия дигәннәре,
Сугыш дигән гыйбрәтләр...


Шашты дөнья, зәхмәт сукты
Ахры кайбер илләрне.
Безнең башка төшә тора,
Денгә кертү,
Шул илдәге ирләрне!

Александр ШУЛЬПИНОВ









Рубльләр бир!

Александр АЛЁШИН

Фәнзаман БАТТАЛ

ЯПКЫЧ

Мәҗлес гөрли... Сый муллыктан
Өстәл тора атынып...
Бер кунагым әледән-әле
Үбеп ала хатынын.

Гаҗәпләнеп утырабыз:
– Мөнә сиңа дивана!..
– Үпкән саен елмая бу!..
– Үпкән саен куана!..

– Утыз ел торган хатынын
Яңа күргән шикелле!
– Булса иде чәчбикәсе
Албастыдан сөйкемле!..

...Көйрәтергә диеп чыккач,
Көлеп куйды шул агай:
– Гаеп итмәгез, туганнар,
Мондый чаклар булгалый.

Теле бик начар хатынның...
Явызның да явызы!
Яшәп булмый ни беләндер
Томаламый авызын...

Вячеслав ШИЛОВ





Николай ВОРОНЦОВ



• • •

Судта.

– Сез нигә банкны таладыгыз?

– Әфәндем, ул беренче булып башлады!

• • •

– Полициядә танышларың бармы?

– Бар – иң якын дустым.

– Ә ул анда нишли?

– Камерада утыра...



Антон МАКУНИ

Коллегалар

Фатирда звонок шалтырады, мин сәгатькә карап алдым – нәкъ ике. Ишек ярыгыннан карадым – ишек артында чибәр генә кызый басып тора иде.

– Нәрсә кирәк сиңа, балакай? – дип сорадым мин ишек аркылы.

– Абый, кунарга кертегез әле, – дип елап җибәрде кыз, – Әнием гүләйт итеп йөргән өчен мине өйдән куып чыгарды.

«Гүләйт иткән өчен – бик шәп бу!» – дип уйлап куйдым мин һәм ишекне ачтым. Кызыйның көпә-көндез "кунарга" җыенуы мине нишләптер шикләндермәде.

Аның артыннан ук фатирга маска кигән өч әзмәвер бәреп керде. Алар инде йодрыкларын йомарлый башлаганнар иде, ләкин мин өлгеррәк булып чыктым:

– Тыныч кына, егетләр! Кирәк әйберләрегезне алыгыз да, ычкыныгыз моннан!

Минем көтелмәгән кыюлыгым егетләрне бераз суытты бугай, алар мине калдырып, өстәл тартмаларын, киштәләрне, шкафларны актарырга керештеләр...

– Бик бай яшәмисез икән, абзый! – диде берсе.

– Әйт хәзер үк, бәдбәхет, кыйммәтле әйберләрең кайда?! – дип кычкырды икенчесе, яңадан миңа таба омтылып.

– Барысы да шушында, – дидем мин, аның йодрыгын этәреп, һәм киштәдәге китапларга күрсәттем. – Алыгыз! Китап – белем чыганагы ул! Ә белем – дөньяда иң кыйммәтле нәрсә!

Минем китапларым белән бергә януымны теләп баталаучылар, сүгенә-сүгенә, ишеккә таба атладылар һәм фатирдан чыгып киттеләр.

Ишек артында адымнар тынды. Мин телефон трубкасын алдым һәм 002 номерын җыйдым.

– Алло, полицияме бу? – дип сорадым мин. – Әле генә фәлән урамда, фәләненче фатирны бастылар! Җинаятьчеләрнең билгеләре... – Аннан соң мин бәйнәбәйнә бандитларның һәм кызның кыяфәтләрен тасвирладым.

– Ә кем шалтырата? – дип сорады телефондагы тавыш.

– Күршеләре... – дидем мин һәм тиз генә трубканы куйдым.

Мин йорттан чыктым, почмак артына борылдым һәм мине сәгать буе иптәшем көтеп торган машинага кереп утырдым. Мин нәкъ тегеләр бәреп керер алдыннан бу фатирда табылган акча, алтын әйберләрен бау белән төшерергә өлгергән идем инде...

– Тотмадылармы? – дип сорады ул, машинасын кабызып урыныннан кузгалып китте.

– Тоттылар. Ләкин безне түгел... – дип елмайдым мин.

– Ничек? – дип гаҗәпләнде иптәшем.

Миңа, оста йорт карагына, ниндидер малай-шалайның үземә һөҗүм итә язганын гына сөйлисе калды.

Каршыга, әле генә без киткән йорт юнәлешендә, ике полиция машинасы узып китте...

Вячеслав ШИЛОВ



ФИРДӘВЕС ЗАРИФка – 60 ЯШЬ



Фирдәвес, дәү ус,
60 ыңны узып кит!
Каләмең тырыш,
Тик ник аз язасың бик?..

Кыяфәтең тач
Гогольгә охшаган кук.
Әсәрләрең дә
Шуныкыдай – тугел чуп!

Толстой яшенә
Житкәнче син яз да яз!
Жуйма дәртеңне –
Син кебекләр илдә аз...

Алмаз ХӘМЗИН

Михаил МИХАЙЛОВ

ХАТЫН МОНОЛОГЫ

Бераз соңрак уяндым.
– Мәче кебек йоклыйсың!
Эшкә чыгып киткәндә үбеп алдым.
– Уяулыгымны киметмәкче буласың!
Аның чибәрлеге турында бер-ике сүз әйттем.
– Мин һәрвакыт шундый!
Кочакладым.
– Яшьлек ялгышы турында искә төшермә!
Чәчәк бүләк иттем.
– Берәр кыек нәрсә эшләдеңме әллә?
Чираттагы тапкыр ничек яратуым турында әйттем.
– Ниһаять, егерме ел эчендә беренче тапкыр!
Эштән шалтыраттылар.
– Сөяркәңме?
Урамда нидер сораган кешегә җавап бирдем.
– Мине гел тыңламыйсың, ят кеше-ләр синең өчен мөһимрәк!
Күрше хатынына сүз каттым.
– Оялмыйча чит хатыннарга бәйләнә-сең!
Эштә күтәрделәр.
– Күпме көч түктем...
Озак еллар буе эшләгән өчен орден бирделәр.
– Бу миңа – синең белән яшәгән өчен!
Бәйрәм өстәле янында җыелдык.
– Минекеннән дә шәп ир юк дөньяда!..

ЮЛБАРЫС ЕЛЫ БЕЛӘН!

Яңа ел белән иң беренче булып күршем Гаптери котлады.

– Яңа ел белән сине, күрше! Иске үпкәләрне онытып, тату яшик. Юлбарыс елы булса да койма аша ырылдашып яшәмик, дөньялыкта килешик, – ди бу.

Ярты ел буе сөйләшми йөргән күршемнән шундый сүзләр ишеткәч, күңелләр тулып китте. Күп кирәкмени адәм баласына.

– Яхшы, – мин әйтәм, – быелдан башлап мин дә синең тавыкларга таш атудан туктармын. Теге чуар тавыгыңны җәй көне, ни, мин бәреп үтергән идем. Үпкәләрсең, дип, соңыннан урамга томырдым.

– Анысы синең алда минем дә гаебем бар, күрше. Көз көне кәҗәңнең аягын мин сугып имгәттем бит. Купкан рәшәткә табып, бакчадагы бөтен кәбестәләрне кимереп чыккан иде. Сизмәсен, дип, кәҗәңне аннары урамга чыгарып җибәрдем.

Моны ишеткәч, күз алларым караңгыланып китте. Ачудан буылыр хәлгә җиттем хәтта. Ярсымас җирдән ярсырсың, көненә 5 литр сөт бирә торган затлы нәселле кәҗә иде бит ул. Башта бер генә уй: "Ничек үч алырга?!" Әһә, җае чыкты. Гаптерине күргә ярсып өрергә тотынган Сарбай янына йөгереп килеп, аны бәйдән ычкындырып җибәрдем. Гаптери, куркуыннан, капканың кай якта икәнен дә онытып, коймага үрмәләде. Инде менеп җитеп, урамга сикердем дигәндә генә, кадакка эләгеп, өр-яңа тунының чабуы аерылып китмәсенме!

Ничек кабынсам, шулай тиз суындым да. Сарбайны тотып, сарайга яптым.

Күршем еламый гына:

– Баҗай кичә генә алып кайткан иде, җитмеш мең тора, – ди.

– Кичерә күр, зинһар! Коймага үрмәләрсең дип башыма да китермәгән идем. Иртәгә үк ике арага ишек ясап куям. Сарбай өрсә дә тешләми ул, куркыта гына. Әйдә, безгә керик әле. Ни дисәң дә Яңа ел бит бүген.

Өйгә кереп юлбарыс тотарлык кәефләнеп алгач, Гаптери дә тынычлана төште:

– Ярар инде, тун дип үлеп булмый, күрше хакы кыйммәтрәк тора, – ди.

Тиз генә бәллүр чәркәләрне тутырдым да, хатын әзерләгән юлбарыс салатын күршем алдына куеп, тост әйттем:

– Кәҗә мал түгел, баҗай туган түгел!

Миңа Гаптери дә кушылды.

– Баҗай малы җәл түгел!



Ринат АБЗАЛОВ

Абау!

КЫЙММӘТЛЕ МИРАС

Краснодар өлкәсенең Челбасская авылында яшәүче ханымның йорт белән бергә мирас итеп калган 300 кг кыйммәтле продукт – шикәр комын урлаганнар. Ләкин шикәр сакланган урынын карагач, аның урланганын аңлаган. Шикәр белән бергә утын кисә торган пычкыны да алып чыгып киткәннәр. Каракларны шундук тотканнар. Алар пычкыны сата алмаган, ә менә шикәр тиз арада таралган... Кирәкле продуктны хуҗага кире кайтара алмаганнар.

ӘДӘПСЕЗ ДӘРЕС

Чиләбе мәктәпләренең берсендә беренче сыйныф укучыларына әдәпсез сүзләр рөхсәт ителмәве турында дәрес бирелгән. Укытучы балалардан белгән сүзләрне санап китүне сораган. Сүзләр агымы күптөрле булып чыккан, хәтта укытучының тел байлыгын да арттырган. Ата-аналарның ачуына җавап итеп, укытучы дәреснең максаты – балаларны әдәпсез сүзләр куллануда туктату, һәм бу мәктәп директоры белән килешенеп эшләнгән. Кирәкле нәтиҗәгә ирешүләре турында укытучылар хәбәр итмиләр.

ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘРДӘ

Северодвинскиның янгын сүндерү бүлегенең начальнигы дүрт ел хезмәттәшләрен бушка эшләткән. Соңгылары рәсми һәм шәхси вакытта "эштә янганнар", начальникның йортын салганнар һәм бина ремонтлаганнар. Алар начальникка каршы барырга батырчылык итмәгәннәр, чөнки аларга төзелештә эшләгән өчен акчалата пособие биргәннәр. "Гадәттән тыш хәлләр"дә эшләгән өчен начальник эшләүчеләрдән премиянең бер өлешен бирүне таләп иткән.

СОРАУНЫҢ БӘЯСЕ

Ростов өлкәсендә ун ЮХИДИ хезмәткәрен кулга алганнар. Алар талауда һәм 14 миллион сумлык ришвәт алуда шикләнеләләр. М4 "Дон" трассасында алар транзит машиналарны фотога төшергәннәр, һәм "ярдәмчеләр"дән график редактор ярдәмендә юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозганнарны ясаганнар. Рәсемнәр машиналар юлында булган ЮХИДИ инспекторларына җибәргәннәр. Алар машинаны туктатканнар, машина йөртүчеләрне хокук бозуда гаепләгәннәр. "Мәсьәләне урында чишү" бәясе биштән – биш йөз мең сумга кадәр булган.

Валерий ТАРАСЕНКО



"Чаян" журналына "Чаян"ча эпиграммалар

Алмаз ХӘМЗИН

Яздырып алмасаң "Чаян",
Шатлыгың булсын каян?

Эчә иде, тарта иде,
Гүләйт итте һәм дә ки:
"Чаян" укып кына Кеше
Булды бит ул, билләһи.

Заманалар авыр, еллар ябык...
"Чаян" кирәк хәсрәт кичәргә.
Өйрәт, күрсәт матур яшәү рәвешен
һәм хәмерне азрак эчәргә!

Минем төсле җор һәм тапкыр кеше!
Хикмәте нидә икән?..
Әй, чукынчык! Миңа әйтми генә
"Чаян" алдырган күптән!

Владимир ТИХОНОВ



Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Сагынырсыз әле...

Исемем – Шакирҗан. Ләкин мәктәп яшеннән миңа ике кушамат ябышып калды. Берсе – Саескан, икенчесе – Тукран. Нигә шулайдыр? Аңлап бетермим. Көнләшүләреннән кушканнардыр.

Исемдә беренче бирелгән кушамат... Мәктәп еллары. Контроль эш эшлибез. Барысы да күчерә. Аларга "бишле", миңа "өчле". Кая дөреслек?

– Апа, – дим укытучыбызга, – алар барысы да күчереп утырды, ник аларга "бишле", ә миңа гына "өчле"? – дим.

– Ул да күчерде, күчерде! – дип такылдадылар классташларым. – Күчерә белмәгәч, кешене гаепләмә, Саескан.

Шуннан үз исемемне оныттылар да шикелле. Саескан кушаматы мәктәпне бетергәнче артымнан ияреп йөрде.

Мәктәпне тәмамлап, институтка кердем. Бу юлы инде бераз саграк булдым. Группа алдында сүз йөртмәдем. Тик шыпырт кына укытучыларга җиткерә идем. Менә группадашлар каян белгәндер? Тагын шул Саескан кушаматы кайтты үземә. Ярар, ни дисәләр дә, әйтсеннәр. Мин үз эшемне эшли тордым. Укып бетергәч эшкә урнаштым.

Эшем авыр түгел иде. Дусларым юк. Кеше белән бик аралашасы да килми. Берсе белән генә. Ул мине эшкә кергәннән алып, үзе белгәннәргә өйрәтте. Бераз дус булдык дип тә әйтергә була. Кимчелеге генә бар: кешегә ышана. Шулай бервакыт салып утырганда, түзмәдем:

– Бигрәк тә беркатлы инде син, дус. Хәзерге заманда бер кешегә дә ышанып бетәргә ярамый. Хәтта миңа да. Дөресен әйтәм, мин бит күп нәрсәне начальникка сөйләп барам.

– Әллә белми дип уйлыйсыңмы? – дип көлеп куйды дустым. – Кушаматың нинди икәнен беләсеңме? Тукран! Син начальникка барысын сөйләп барганын барыбыз да белә. Шуңа күрә ярамаган нәрсәне сиңа сөйләмим, бик сөенеп утырма.

Вәт бит нинди, ә? Әле дус булып йөри тагын. Мин аны барысын да сөйли дип торам.

Аңа да карамастан, начальник хөрмәт итә үземне. Киңәшә. Эшебездә нәрсә булганын, кем нәрсә сөйләгәнен мин генә җиткерәм бит. Хәзерге заманда башкача булмый. Мин сөйлим, эш бара. Кайчагында үземә премия дә биреп куялар. Башкалар зарланса да: "Ник, нәрсә өчен аңа премия бар? Сүз йөрткән өченме? Без эшлибез, ул акча ала!"

Пандемия вакыты башланды. Олы яшемдә булгач, өйдән генә эшләдем. Алай да, эштә нәрсәләр булганын белеп тордым. Һәм барысын начальникка җиткердем.

Менә пенсия вакыты да килеп җитте. Мин киткәндә эштәгеләр шатланды:

– Тукраныбыз китте. Хәзер тыныч эшләсәк тә була!

Бик сөенмәсеннәр. Минем урынга башка Тукраннар да табылыр. Сагынырлар әле үземне.



Анатолий НЫРОВ

ҮТКӘННӘРГӘ КАРЫЙК КАЕРЫЛЫП

«Чаян» һәрвакыт эчкечелеккә каршы көрәшеп яшәде. Бюрократлар һәм ялкаулар белән берраттән, хәмер сөючеләр чаянчыларның аяусыз уты астында булды. Йөз ел эчендә журналда аларга багышланган күпсанлы үткен карикатуралар, зәһәр фельетоннар һәм шигырьләр чыгып килде. Нәтиҗәдә, безнең тырышлыклар әрәмгә китмәде шикелле. Һәрхәлдә, безнең бөтен нәрсәне белеп торучы статистика белдерүенчә, ватандашларыбыз каты эчемлекләр эчүне киметеп, җиңелрәкләренә күчә башладылар. Ә "өч борынга" берләшү күренеше гомумән безнең тормыштан юкка чыкты. Бу казанышларда, һичшиксез, безнең дә кечкенә өлешебез бардыр дип уйлыйсы килә. Әмма аек акыл һәм саф күңелләр өчен көрәш соңгы сәрхушкә кадәр дәвам итәчәк! Ә хәзергә бу көрәшнең төрле еллардагы мизгелләренә күз салып үтегез.

В. ИГНАТЬЕВ, 1965 ел.



Эш атмосферасында

Э. ГЕЛЬМС, 1965 ел.



– Бер шешәдән аягыңда тора алмыйсың!

Л. ЕЛЬКОВИЧ, 1963 ел.



Яңа мәхәббәт

А. ЛУТОВ, 1961 ел.



– Мондый байлыктан егылып китәм!

В. ИГНАТЬЕВ, 1962 ел.



– Сезне нәрсә борчый?
– Йөрәк-кан тамырлары системасы!



Т. ФӘИЗОВ, 1984 ел.

И. БОБРОВИЦКИЙ, 1963 ел.





• • •

– Син кемне күбрәк тыңлыйсың, әниеңнеме әллә әтиеңнеме?
– Әнине.
– Ни өчен?
– Ул күбрәк сөйли.

• • •

Кибет мөдире әле генә эшкә алынган яшь сатучы кызны ниндидер ярамаган эше өчен битәрли:
– Синең аз гына булса да намусың бармы?!
– Бар, мин сәүдәдә яңа гына эшли башладым.

• • •

– Минем кызым җырчы булырга хыяллана, бүген ул җыр дәресләре алырга башкалага китә!
– Башкалада уку бик кыйммәткә төшәдер бит?
– Әллә ни түгел, бөтен чыгымнарны күршеләр күтәрде.

• • •

Минем организмны аңламассың. Диванны күрү белән ятып торасы килә башлый, сыра күрсәм – эчәсе, ашамлык торса – ашыйсы. Ә менә эш эшлисе булса – йокы килә.

• • •

Күршеләр ачуны китерә! Борауламыйлар да, музыка да тоташтырмыйлар, эчмиләр, талашмыйлар. Шундый уй туа: әйтерсең, утырганнар да тыңлыйлар.

• • •

Кәгазьнең кыйбатлануыннан подъезддагы почта тартмаларындагы спам бетте. Ичмасам, бер яхшы ягы бар...

• • •

– Тырыш, кызым, хәрефләрне матур итеп яз...
– Әтием, минем табиб буласым килә.

• • •

Минем икенче хатыным шулхәтле көнче иде, менә шуңа беренче хатын белән бернәрсә дә булмаганын гел исбатлап тордым...

• • •

– Сез нәрсә белән кызыксынасыз?
– Сәясәт белән.
– Актив рәвештәме, әллә пассивмы?
– Нинди мәгънәдә?
– Депутат буларакмы, әллә болай гынамы, телевизор гына карыйсызмы?











АГА СУЛАР НИК БОЛАЙ...

Кадерле редакция! Турист булган һәр кеше Илет елгасының матурлыгына сокланып туя алмый. Ул "Мари Чодра" милли паркы аша ага. Аның табигый гүзәллеге беркемдә дә шик уятмый, кайчандыр Илет Европадагы иң чиста елгаларның берсе булып санала иде.

Быел да шулай булды. 9 апрель көнне, быелгы кар катламыннан ниһаять арынып, шәһәр ыгы-зыгысыннан туеп, без, бер төркем Казан туристлары, Красногор бистәсе күперенең астында төялеп, ишкәкләрне суга төшердек тә, күкрәк тутырып саф һава сулап, йөзәргә керештек. Ләкин без көтканчә түгел икән шул хыяллар: кинәт борынга әллә нинди авыр ис бәреп керде, бәлки, тора-бара бетәр дигән уйлар да акланмады, каршы искән җилгә ияреп көчәйде генә. Елга суының төсе дә болганчыкланып яшелләнде, күбекләнде һәм корсагы кабарган зур гына балык дулкында тирбәлә иде. Кире борылырга, ярга чыгып кабат кайтып китәргә дә мөмкинчелек калмады – ярларда калын-калын боз катламнары, эреп бетмәгән кар кыялары ята. Нишләмәк кирәк, ярларны тәртеп чыккан канализация торбаларындагы суларга манчылып, сәяхәтне ирексездән дәвам итәргә генә туры килде.

Сәяхәтебезне тәмамлаган Короткова авылы халкыннан бу әшәке исле суларның Красногор бистәсе янышнан агып чыкканын белдек. Андагы чистарткыч корылмалар һәм каналларның төзеклегенә хәтерең калырлык – елганың иске тармагы аша яңадан Илеткә кушыла. "Өстәгеләргә зарланып та карадык, тыңлаучылар гына булмады, бер айлап вакыт үткәч сунын чисталыгын тикшереп карыйлар, һәм барысы да нормада", – дип әйтәләр.

Интернетта бер хәбәр бар: моңа охшаш хәл 2017 елда бер булган икән инде. Елгага бик күп шундый шакшы сулар аккан шул Красногоркадан. Ул чагында Звенигов районы хакимияте чистарту корылмалары ремонтлау өчен 19 млн. акча кирәклеген әйткән. Проектын республика программасына да керткәннәр.

Күрәсең, эш шуннан ары алга китмәгән, "мари энҗесе"нең бүгенге хәле шуны искәртә. Хәзер карларның көчле эрү вакыты, димәк, бөтен әлеге "искитмәле ис ташкыны" Идел буйлап безгә дә килеп җитәр. Ничек дисезме? Илетнең Иделгә кушылган тамагы Яшел Үзән шәһәреннән өстәрәк...

Бер төркем туристлар

КАЗАН

Дамир МОРТАЗИН

Рецензия

– Ничек анда эшләр? – дип сорады Җирле фәннәр академиясенең бүлек мөдире Вәлитов өлкән фәнни хезмәткәр Бәлешевтән.

– Менә! – диде, шатлыклы кыяфәт белән "Җирле фән хәбәрләре" журналын шефына сузып, монысы.

– Нәрсә бу? – дип әйтеп куйды Вәлитов, аптырагандай.

– Онытканмын сезгә күрсәтергә. Ике ай чамасы элек чыккан иде сезнең монографиягезгә минем рецензиям. "Дөнья фәненә җирле фәннән кыйммәтле өлеш" дигән эшегезгә.

– Хәтерләмим, нинди монография?

– Соңгысы да булмастыр... – диде бераз кыенсынгандай Бәлешев.

– Акылыгыздан шаштыгызмы әллә! – дип кырт кисте аны башлыгы.

– Нигә алай дисез? – дигәндәй гаҗәпләнде хезмәткәре.

– Әле китап чыкмаган да бит! Чыкмаган да!

– Алай бик аптырамагыз әле. Уңайсызрак килеп чыкты чыгуын... – өлкән фәнни хезмәткәр бераз моңсулангандай булды, уйга калды, акылына килеп:

– Борчылмагыз инде, берәү дә берни сизмәс...

– Ничек инде сизмәс?! – дип тавышланырга тотынды бүлек мөдире. – Бөтенесе, мөгаен, укыганнардыр! Телләрендә гел шулдыр! Нинди хурлык – рецензиясе бар, ә монографиясе юк!

Шулчак Бәлешев ышанычлы итеп:

– Сез бит үзегез әле укымадыгыз! – дип куйды.

– Билгеле, юк...

– Менә алар да укымаган, белмиләр...

– Бәлки эндәшмиләр генәдер...

– Сизгән, белгән булсалар күптән тавыш күтәргән булырлар иде инде – фәнни буллинг куптарырлар иде!

– Нәрсә соң ул буллинг? – дип, шикләнеп кенә сорады бүлек мөдире..

– Анысы мөһим түгел... Бер яхшы мәзәк сөйләсәм әйбәтрәк булыр: "Ире командировкага киткән..."



Виктор ФЁДОРОВ



Бари Рәхмәт – татар поэзиясенең күренекле вәкиле.

Бари Рәхмәт 1897 елда Казакъстанда туа. Башлангыч белемне мадрасәдә ала. Кечкенәдән үк Тукай әсәрләрен яратып укый, үзе дә шигырьләр языштыргалый башлый. 1914 елда Казанда чыга торган балалар журналы «Ак юл»да яшүсмер егетнең беренче шигыре дөнья күрә.

1921 елда демобилизацияләнгәч, булачак шагыйрь туган якларына кайта. 1932 елда гаиләсе белән Казанга күчеп килә. 1939 елдан башлап «Чаян» һәм «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналларында аның сатирик һәм лирик шигырьләре күренә башлый.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Б. Рәхмәт фронтка китә, анда фронт газетасында эшли.

Шагыйрьнең сугыш чоры лирикасында һәм сугыштан соң язган әсәрләрендә иҗатының нигезендә яткан халыкчан табигыйлек, нечкә юмор белән сугарылган шигъри фикерләү һәм тасвирлау үзенчәлекләре тагын да ачыла төшә.

Илленче еллардан башлап алты җыентыгы дөнья күреп, Б. Рәхмәт тиз арада иң яратып укыла торган язучыларның берсенә әверелә.

Бари Рәхмәт шигъри таланты тәмам ачылып җиткәндә, 1957 елның 26 маенда кинәт вафат була.

Ул 1952 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы иде.

БАРМАГЫҢА АКЧА ТҮЛИМ

Басып торам каршыңда,
Күзем бармакларыңда.
Бар икән бармакларыңда
Алтын балдакларың да.

Күмәч үлчисең шарт та шырт,
Карап торам шаккатып.
Бер аласың, бер саласың
Сыныкларны шалт та шылт...

Бармакларыңны, җанашым,
Күмәч белән саласың.
Шалт иттереп саласың да,
Ялт иттереп аласың.

Бармагыңны ник саласың,
Салгач кире аласың.
Мин бит акча түлим аңар,
Алмасана, җанашым!

БЕЗНЕ КӨТӘЛӘР

Безнең сулар, безнең кырлар анда,
Безнең басу, безнең ындырлар;
Чәчәк ата безнең гөлләр анда,
Үстерәләр безнең яңгырлар.

Көннәр – безнең көннәр,
таң – безнең таң,
Безне сагынып ата, саргаеп.
Караңгысын җәеп төн-партизан
Килмешәкне борчый көн саен.

Ярсып тибә безнең йөрәк анда,
Безнең күкрәк белән сулый җир.
Курку салып дошман йөрәгенә,
Безнең тавыш белән шаулый җил.

Дошман анда зәһәр сулыш ала,
Котырган ул, күзе каныккан,
Безне җиңалмагач, үчен ала
Анда калган безнең халыктан.

Аның ерткычлыгын язсаң әгәр,
Кан тамар күк тоела каләмнән,
Кан исләре аңкыр кебек тоела
Ак кәгазьгә тамган карамнан.

Анда таң да елап, сыкрап ата,
Кояш чыга сытып чыраен.
Шәфәкъ, әйтерсең лә, канга бата,
Ай боегып калка, моңаеп.

Әчкә баткан күзләр, сулган йөзләр,
Хәсрәт чиккән хәлсез аналар
Көтә безне, тизрәк килсеннәр, дип,
Көтә, тилмерешеп, балалар.

1944

ТӘМӘКЕНЕ НИЧЕК ТАШЛАРГА

Тәмәкене ташларга
Кушалар врачлар да,
"Лекция" укый хатын да,
Шул тәмәке хакында.

– Сиңа нәрсә булгандыр,
Ике пачка "Беломор"
Көн саен син ашыйсың,
Күпме расход ясыйсың.

Бик күп китә акча, – ди,
Җитәр инде, ташла, – ди.
Ике пачка "Беломор"
Җитми әле миңа ул.

Мин ташламакчы булып,
Йөрдем конфет та суырып,
Канәфер чәйнәп бактым,
Чимәнкәсен дә чактым.

Һич тә ташлап булмый бит,
Көн бер кило конфет,
Яхшы шоколад ашыйм,
Имеш, тәмәке ташлыйм.

Өйрәнеп китте авыз,
Тәмлесен тели, явыз.
"Беломор"ны ташладым,
"Казбек" тарта башладым.

ӘБИ БЕЛӘН БАБУШКА

Ике карчык гөрләшәләр тышта,
Берсе – әби, берсе – бабушка.
Берсе оек, берсе чулок токан,
Икесе дә оста бик эшкә.

Дуслар да бик: пирог пешкән көнне
Әбине дә дәшә бабушка.
Бәлеш пешкән көнне бабушканы
Әби дәшми калмый бәлешкә.

Белгән сүзен русча, белмәгәнен
Үз телендә әби сукалый,
Ә бабушка, аңлаган күк аны,
Башын селки, күзен кыскалый.

Әби көлсә, ул да көлгән була,
Белмәсә дә нигә көлгәнен.
Күгәрчен күк гөрли-гөрли шулай,
Уздыралар бергә көннәрен.

ХАТЫН ОРЫША

Мәхәббәт турында яз, диләр,
Андый җырлар бездә аз, диләр.
Мин үзем язарга тырышам,
Язып булмый... Хатын орыша.
– Мине сөйгән чакта язмадың,
Инде карт көнеңдә язма, – ди.

Ләбиб ЛЕРОН

МАРСЕЛЬ ГАЛИГӘ... ҺӘЙКӘЛ?

Дөньяның иң бай кешесе, түбәндәге сүзләрен әйтер өчен генә дә, татарча сөйләргә өйрәнеп:

– Марсель Гали әфәнде, ун томлык китабыңны супертышлык белән иң затлы кәгазьдә, иң зур тираж белән, иң данлыклы типографиядә нәшер кылдырып бирәм, үзеңә фәлән-фәлән миллион доллар гонорар түлим, туган ягың Азнакайдагы Чатыр тауга үземнең дә төшкә кермәгән вилла салдырып, үзеңне Җир шарына мәшһүр итәм, әгәр дә син бер генә көн булса да телефоннан сөйләшмичә һәм үз-үзеңне мактамыйча торсаң, – дисә дә, Марсель Гали барыбер телефоннан сөйләшер, үз-үзен мактар иде.

Менә әле дә ул "Салават күпере" журналы редакциясенең баш мөхәррире Зиннур Хөснияр телефонының санлы тәгәрмәчен озынча имән бармагы белән зырылдата-зырылдата, телефон көпшәсенең тыңлый торган өлешен авызына, сөйләшә торганын колагына терәп сөйләвен белә:

– Ризван Хәмиднең – Язучылар берлегендә урынбасар, минем һөнәрмәнд, ягъни профессиональ язучы буларак беркайда да эшләмәгән чак. Рөстәм Мингалимне дә алып киттек без Горький паркына очрашуга. Халык, мин киләсен әллә каян ишетепбелеп, шактый җыелган иде. Минем затлы сүзләрне зар-интизар булып тыңларга әзерләнгән шул халыкны Ризван Хәмид иң әүвәл үзе белән таныштырды: "Язучылар берлеге рәисе урынбасары, идарә әгъзасы, М. Җәлил исемендәге комсомол бүләге лауреаты, танылган драматург – "Китәм инде", "Кайтам инде", "Китмимен дә, кайтмыймын да", "Әллә китәргә микән?", "Бәлки, тагын кайтырмын" кебек чутсыз пьесалар авторы..." Ризван, пьеса исемен әйткән саен, халыкка: "Бәлки, карагансыздыр спектакльне?" – ди. Миңа мөкиббән булып утырган халык – ләм-мим. Аптырагач, Ризван Хәмид халыкка мине тәкъдим итәргә кереште: "Марсель Гали – шагыйрь, прозаик, бик күп китаплар авторы, Язучылар берлеге каршындагы бердәнбер стена газетасының баш мөхәррире..." Шуның белән вәссәлам! Ә халык... Ә халык гөрләтеп кул чаба! Луиза Батыркай җырга әйләндергән "Су буеннан әнкәй кайтып килә" дигән мәшһүр шигыремне укыгач, халык, сагышлы күз яшьләрен импортный күлмәк җиңнәре, күпсанлы һинд яулыгы читләре белән сөртә-сөртә, отыры күңелле гөжләргә тотынды...

Әлеге очрашу хакындагы хикәятне инде туксан бер мәртәбә бирелеп тыңлаган каләмдәшләренең монысында битараф кына колак салып, үзара ни турындадыр гәпләшеп утыруын күргәч, Марсель Гали, төтен чыгар дәрәҗәгә җиткән телефонны янә тетрәтә-тетрәтә, үпкәчел тавыш белән:

– Белмисез бердәнбер затлы язучыгызның кадерен. Бөек башым белән сезнең янда йөргән мин җүләр!..

Мөһим эше буенча телефоннан шалтыратырга интегеп, бу хакта Марсель Галигә әйтергә кыенсынып утырган Зиннур Хөснияр:

– Әле генә Сәйдәшкә җыеп туктаган идек. Тагын һәйкәлгә акча җыясы була икән, – ди.

Валерий ТАРАСЕНКО



Михаил ЛАРИЧЕВ





САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 5 (1918) май 2022

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде. Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылып алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 28.04.2022 ел.
Тираж – 2685 Заказ О-1204

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!

АРТИСТ ИЛЬЯСБӘК КУДАШЕВ-...

КОМПОЗИТОР ... МӘҖИТОВ

АТТАН ... ДА ТУА КОЛА ДА ТУА

ТУКАЙ КАТНАШКАН ЖУРНАЛ

ХАЛЫК ЖЫРЫ "... УРМАН"

ЯКЫН КӨНЧЫГЫШТА ДӘҮЛӘТ

ЮАН БАУ

КОМПОЗИТОР ... ДАУТОВ

КЕТӘК ХУҖАСЫ

ТАШ АТКАНГА ... АТ

... ӘЛМИЕВ "ТУГАН ..."

ТӨРКИЯДӘ ШӘҺӘР

"ЧАЯН" ВЕТЕРАНЫ ... ЗӘКИЕВ

НОТА

"АГЫЙДЕЛНЕҢ ПАРОХОДЫ, БЕЗДӘН ЕРАКТА ..."

"... ЕГЕТЛӘР"

"... БӨГЕЛЕП ТОРА"

"СУТЫЙ"

"ТӨРПӘТЕП ЯШИСЕ БАР ..."

ГАУГА

ШАГЫЙРЬ ... ГАМБӘР

РЕСПУБЛИКАБЫЗ "... ИКЕ БЕЛӘГЕМ"

ТӘБРИКЛӘҮ

"ГОМЕР (-1) ..."

"КҮЗГЕ ... ЖИЛЛӘРДӘ"

"УЙНЫЙ ... (-1) БӨРТЕКЛӘРЕ"

ТАРТТЫРЫЛГАН ЯРМА

КИНОАКТЁР БРЮС ...

"КОШЛАР ..."

ХАТЫН, ХУҖАБИКӘ

МЕНӘ СИҢА ...!

"... НЫҢ ЯКТЫ НУРЫ ТӨШӘ"

... МӨЛЕКОВ

АРТИСТКА ГӨЛСЕМ ...

Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Пешекче белән табиб арасында нинди уртаклык бар?

2. Реклама – сәүдә этәргече, алга җибәрүче, диләр. Дөресме бу?

3. Кышкы балыкчы белән җәйгесенең аермасы нәрсәдә?

4. Бакчадагы күршеләр кемнәр алар?

5. Видеокамералар, полиция, тимертаптыргычлар, бикле ишекләр, бадрәфкә сакчы белән йөрү. Нәрсә бу?

6. Әңгәмәләшү белән гайбәт арасында нинди аерма?

7. Сезнең барысы да тәртиптә дип санаган табибны кайда табып була?

ҖАВАПЛАР

1. Әгәр дә алар эшләрен яхшы башкаралар икән, яннарына керүчеләр тернәкләнәләр. 2. Юк. Төп этәргеч – халыкның, котырынып, кибетләрне бушатуы. 3. Алар икесе дә бер үк халдә – исерекләр, кышкысы – итек белән. 4. Мифологик затлар, кирәккәндә генә күренеп алалар, әмма бакчадагы барлык эшләр һәрвакытта тиешенчә үтәлгән була. 5. Мәктәптәге бердәм дәүләт имтиханнары! 6. Әңгәмә – өч сердәшнең бергә очрашып сөйләшүе. Гайбәт шуларның берсе китеп баргач башлана. 7. Хәрби комиссариатта.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 4 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«ГАЙНАВАЛ ЖЫРЫ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Н. ЙОСЫПОВА (Арча р-ны, Яңа Кишет ав.),
Р. САФИН (Балык Бистәсе, Полянка ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан),
Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.),
Р. ЯРУЛЛИН (Апас).

Җиңүчебез – Апастан **Рәис ЯРУЛЛИН!**





Александр ШУЛЬПИНОВ



Сергей АНДРИАНОВ



Инспектор машина туктата:

– Ханым сез тизлекне 40 километрга хәтле чикләүче билгене күрдегезме?

– Әйе, тик мин аны пошилар өчен дип уйлаган идем...

– Нинди пошилар?

– Узган билгедә ясалганнар...

Сергей ЕРМИЛОВ



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



